**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592)
7-20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail:
aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-
20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail:
aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«23» апрель 2020 ел** **№135**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре - Елга авыл җирлеге
Генераль план проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Кәкре -Елга авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2020 елның 30 апреленнән 2020 елның 1 июненә 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны: Азнакай районы, Кәкре- Елга авылы, Совет ур., 22 йорт;

-фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020 елның 1 июненә кадәр кертелергә мөмкин булган адрес: Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев урамы, 24 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге; Азнакай районы, Кәкре Елга авылы, Совет урамы, 22 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы Кәкре -Елга авыл җирлеге башкарма комитетына:

-Азнакай муниципаль районы Кәкре -Елга авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча, гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә, ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Кушымта нигезендә Азнакай муниципаль районы Кәкре - Елга авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

6. Әлеге карарны "Татарстан http://pravo.tatarstan.ruРеспубликасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М. З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
башлыгы карарына кушымта
« ___» _______ 2020 №_____

Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышу, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А. Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р. Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С. Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов И. М. | Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай район Советының җирлекләр белән эшләү секторы мөдире |